КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2024 ел, 12 ноябрь г.Казань № б-2456

Татарстан Республикасы Рәисенең «Кол Галинең тууына 850 ел һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга 800 ел тулуны бәйрәм итү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 905 номерлы Указын үтәү йөзеннән:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2033 елда Кол Галинең тууына 850 ел һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга 800 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү чаралары планын (2024 – 2027 елларга) (алга таба – План) расларга.
2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Планны гамәлгә ашыруда катнашуны тәкъдим итәргә.
3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Планны мәгълүмати яктыртуны тәэмин итәргә.
4. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 12 ноябрь, б-2456 нчы
боерыгы белән расланды

2033 елда Кол Галинең тууына 850 ел һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга 800 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү чаралары планы
(2024 – 2027 елларга)

| Т/с | Чара | Үткәрү датасы | Үткәрү урыны | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Татар халык эпосына багышланган «Дастаннар тарихы» видеоязмалары циклын булдыру | 2024 ел | – | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы |
| 2. | «Татарстан радиосы фондларыннан» тапшырулар циклын булдыру:<br>«Кыйссаи Йосыф» (радиоспектакль);<br>«Йосыф белән Зөләйха» (радиокомпозиция);<br>«Кыйссаи Йосыф» (радиокомпозиция);<br>«Кол Гали» (Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакленең Татарстан Республикасы халык язучысы Нурихан Фәттах әсәре буенча радиоварианты);<br>«Якутлардан кыйммәтрәк» (радиокомпозиция) | 2024 – 2027 еллар | – | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| 3. | 2033 елда Кол Галинең тууына 850 ел һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәре язылуга 800 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм үткәрү кысаларында Татарстан Республикасы муниципаль районнарында чаралар оештыру һәм уздыру (аерым план буенча) | 2024 – 2027 еллар | Татарстан Республикасы | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 4. | Урта гасырдагы күренекле болгар шагыйре Кол Галинең тууына 850 ел тулуны бәйрәм итүгә багышланган ачык лекция үткәрү | 2025 елның октябре | Яр Чаллы шәһәре | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 5. | Бөек болгар шагыйре Кол Гали һәм аның мәшһүр «Кыйсса-Йосыф» әсәре күргәзмәсен оештыру һәм үткәрү, Идел буе Болгар дәүләтенең Ислам динен рәсми кабул итү көненә багышланган «Изге Болгар җыены» тантаналы чарасы кысаларында | 2025 ел | Болгар шәһәре | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 6. | Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының 8 – 9 сыйныф укучылары арасында Кол Галинең тормышына һәм иҗатына багышланган «Башваткыч» | 2025 ел | Минзәлә шәһәре | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Муса Җәлил исемендәге Минзәлә педагогика көллияте» дәүләт |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | республика әдәбият конкурсын үткәрү | | | автоном һөнәри белем бирү учреждениесе |
| 7. | «Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесенең гастроль эшчәнлеге кысаларында Россия Федерациясе шәһәрләрендә «Йосыф» спектаклен (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре мотивлары буенча) күрсәтүне оештыру (аерым план буенча) | 2025 – 2027 еллар | Россия Федерациясе | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 8. | «Суфилар шигърияте» лекцияләр һәм дискуссияләр сериясен үткәрү | 2025 – 2027 еллар | Казан шәһәре | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 9. | «Кыйссаи Йосыф» поэмасы һәм татар әдәбияты» темасына «Язучы дәрес бирә» мәгариф проектын гамәлгә ашыру | 2025 – 2027 еллар | Арча шәһәре | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» иҗтимагый оешмасы (Иҗади берлек) (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 10. | Гомуми белем бирү мәктәпләренең, лицейларының, гимназияләрнең өлкән сыйныф укучылары өчен урта гасырдагы күренекле болгар шагыйре Кол Галигә һәм аның мәшһүр «Кыйссаи Йосыф» әсәренә багышланган фәнни-гамәли конференция үткәрү | 2026 елның феврале | Яр Чаллы шәһәре | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 11. | Массакүләм мәгълүмат чараларында Кол Галинең тормышына һәм иҗатына багышланган материаллар бастырып чыгару | 2026 ел | Татарстан Республикасы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы |

---